КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 21 гыйнвар г.Казань № 25

2026 елга «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау һәм «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан «Социаль няня» хезмәте күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2025 ел, 13 октябрь, 827 нче карары нигезендә «Коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан «Социаль няня» хезмәте күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2026 елга «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны бер айга бер хезмәт күрсәтелүчегә 64 749,28 сум күләмендә;

2026 елга «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын бер сәгатькә 399,48 сум күләмендә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 21 гыйнвар, 25 нче
карары белән расланды

«Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны
һәм «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан
финанслау нормативын исәпләү тәртибе турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан «Социаль няня» хезмәте күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2025 ел, 13 октябрь, 827 нче карары (алга таба – 827 нче карар) нигезендә «Коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан «Социаль няня» хезмәте күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыру кысаларында «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү механизмын билгели.

2. «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар законнарда билгеләнгән таләпләр нигезендә «Социаль няня» хезмәте күрсәтү өчен кирәкле финанс чаралары күләменнән гыйбарәт.

3. «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативы «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар нигезендә исәпләп чыгарылган финанс чаралары күләменнән гыйбарәт.

4. «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын исәпләү «Социаль няня» хезмәте күрсәтү тарифын раслау өчен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда бер елга бер тапкыр «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

«Социаль няня» хезмәте күрсәтү тарифы 827 нче карар нигезендә «Коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан «Социаль няня» хезмәте күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыру кысаларында «Социаль няня» хезмәте белән тәэмин итүчегә Татарстан Республикасы бюджетыннан чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия күләмен билгеләү өчен кулланыла.

5. «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар бер айга бер хезмәт күрсәтелүче исәбеннән билгеләнә.

6. «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативы бер сәгать «Социаль няня» хезмәте күрсәтү өчен билгеләнә.

## II. «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе

7. «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар ($NFZ_{sn}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$NFZ_{sn} = R_{FOT_{sn}} + (R_{FOT_{sn}} \times K_{nr}),$$

монда:

$R_{FOT_{sn}}$– «Социаль няня» хезмәте күрсәтүче персонал хезмәтләренең стандарт (база) кыйммәте;

$K_{nr}$ – өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр өчен 0,08гә тигез итеп алына торган өстәмә чыгымнар коэффициенты.

8. «Социаль няня» хезмәте күрсәтүче персонал хезмәтләренең стандарт (база) кыйммәте ($R_{FOT_{sn}}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$R_{FOT_{sn}} = N_{psn} \times O_{sn} \times (1 + e),$$

монда:

$N_{psn}$ – «Социаль няня» хезмәте күрсәтүче персоналның 1гә тигез итеп алына торган штат саны нормативы;

$O_{sn}$ – «Социаль няня» хезмәте күрсәтүче персоналның хезмәте өчен түләүгә әлеге Нигезләмәнең 9 пункты нигезендә алына торган чыгымнар;

e – хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр ставкасы.

9. «Социаль няня» хезмәте күрсәтүче персоналның хезмәте өчен түләү чыгымнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә таянып, өченче пунктның икенче һәм өченче абзацларында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып билгеләнә.

«Социаль няня» хезмәте күрсәтүче персоналның база оклады 653 нче карар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең «Беренче дәрәҗә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеменең беренче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән база окладына туры килә.

«Няня» һөнәре буенча «Социаль няня» хезмәте күрсәтүче персоналга хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә акча вазыйфаи окладның 76 проценты күләмендә билгеләнә.

## III. «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын исәпләү тәртибе

10. «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативы бер сәгать өчен түбәндәге формула буенча билгеләнә: ($PNF_{sn}$)

$$PNF_{sn}= \frac{NFZ_{sn}}{H_{rd}} \times 12,$$

монда:

$NFZ_{sn}$– «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар;

$H_{rd}$ – Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыручы эш бирүчеләр өчен агымдагы елга җитештерү календарендә билгеләнгән 40 сәгатьлек эш атнасы булганда агымдагы елда эш вакыты нормасы;

12 – бер елда айлар саны.

## IV. «Социаль няня» хезмәте күрсәтүне финанс белән тәэмин итүне исәпләү тәртибе

11. «Социаль няня» хезмәте күрсәтүне финанс белән тәэмин итү чыгымнары ($FO_{sn}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FO_{sn} = PNF_{sn} \times P,$$

монда:

$PNF_{sn}$ – «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативы;

P – «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә планлаштырыла торган, бер елга 41 600гә тигез итеп алына торган карау сәгатьләре саны.